**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлеге
Аю торак пунктында 2024 елда гражданнардан
үзара салым кертү турында

**20.11.2023 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Аю торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.2024 елда Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Аю торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерү:

1) Аю торак пунктында Яшьләр, Мәктәп урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш сатып алу, ташу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Аю торак пунктында скважиналар өчен 2(ике) тирәнлек насослары сатып алу;

3) Аю торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http://menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районының
Аю авыл җирлеге башлыгы ____________________ А.М.Галимов
(имза)